КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2023 ел, 30 март г.Казань № б-790

1. Татарстан Республикасы территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына ярдәм күрсәтү мәсьәләләре буенча төбәк ведомствоара комиссиясен (алга таба – Комиссия) төзергә һәм аның составын (боерыкка теркәлә) расларга.

2. Комиссиягә Татарстан Республикасы территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына ярдәм күрсәтүгә бәйле мәсьәләләрне хәл итү эшен координацияләүне тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарына махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына ярдәм күрсәтүгә бәйле вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда Комиссиягә булышлык күрсәтергә, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына Комиссиягә әлеге үз вакаләтләрен гамәлгә ашыруда булышлык күрсәтүне тәкъдим итәргә.

4. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Социаль үсеш идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 30 март, б-790 нчы
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына ярдәм күрсәтү мәсьәләләре буенча төбәк ведомствоара комиссиясе составы

| | |
|---|---|
| Фазлыева Ләйлә Ринат кызы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, комиссия рәисе |
| Мөхәрләмов Руслан Роберт улы | Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Рәисенең Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты җитәкчесе, комиссия рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Айзатуллин Марат Мансур улы | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры |
| Әюпова Ирада Хафизҗан кызы | Татарстан Республикасы мәдәният министры |
| Бәдриев Илдар Фоат улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Социаль үсеш идарәсе башлыгы |
| Бариев Динар Раил улы | «Бердәм Россия Яшь гвардиясе» бөтенроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан төбәк бүлеге җитәкчесе (килешү буенча) |
| Бородин Александр Ильич | «Россия ветераннар берлеге» ветераннар гомумроссия иҗтимагый оешмасының «Татарстан Республикасы Ветераннар берлеге» ветераннар (инвалидлар) республика иҗтимагый оешмасы рәисе (килешү буенча) |
| Вәлиева Зилә Рәхимҗан кызы | Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе (килешү буенча) |
| Вафин Эдуард Яфас улы | «Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге идарәчесе (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Галимова Ангелина Фәрит кызы | Ватан сугышчылары гаиләләре комитетының төбәк штабы җитәкчесе (килешү буенча) |
| Горелик Нахум Ицхак | Казан шәһәре һәм Татарстан Республикасының баш раввины (килешү буенча) |
| Гобәйдуллин Әгъзам Самат улы | «Татарстан Республикасының Муниципаль берәмлекләр советы» ассоциациясе рәисе (килешү буенча) |
| Заһидуллин Рөстәм Илдус улы | Татарстан Республикасы юстиция министры |
| Зарипова Эльмира Әмир кызы | Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры |
| Леонов Владимир Александрович | Татарстан Республикасы спорт министры |
| Миңнуллин Марсель Мансур улы | Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры |
| Кирилл (Наконечный Михаил Васильевич) | Казан һәм Татарстан митрополиты (килешү буенча) |
| Низамов Ригел Хәләф улы | Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча Медик-социаль экспертиза баш бюросы» федераль казна учреждениесе җитәкчесе (килешү буенча) |
| Погодин Сергей Николаевич | Татарстан Республикасы хәрби комиссары (килешү буенча) |
| Садыйков Ринат Наил улы | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министры |
| Сәлимгәрәев Айдар Сәетгәрәй улы | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе |
| Сәмигуллин Камил хәзрәт (Сәмигуллин Камил Искәндәр улы) | Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәте башлыгы, Татарстан мөфтие (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Сөләйманов Тимур Җәүдәт улы | Татарстан Республикасы Рәисе ярдәмчесе, Татарстан Республикасының «Движение первых» балалар һәм яшьләр гомумроссия иҗтимагый-дәүләт хәрәкәтенең төбәк бүлеге советы рәисе (килешү буенча) |
| Фазылов Ринат Рафаэль улы | «РОССИЯ ӨЧЕН» ХАЛЫК ФРОНТЫ» гомумроссия иҗтимагый хәрәкәтенең Татарстан Республикасындагы төбәк бүлеге башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча) |
| Һадиуллин Илсур Гәрәй улы | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры |
| Хәйруллин Газинур Гарифҗан улы | Советлар Союзы Геройлары, Социалистик Хезмәт Геройлары, Россия Геройлары һәм Татарстан Республикасы Хәрби һәм Хезмәт Даны орденнарының тулы кавалерлары иҗтимагый хәйрия оешмасы рәисе (килешү буенча). |

---